**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.07.2015 г. Казань № 01-02/454

**Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

"Аерым категория затларына Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллануны тыю турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы "и" пунктчасы һәм "Коррупциягә каршы торуның кайбер мәсьәләләре турында" Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты, Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында" 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Указы нигезендә, боерам:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әлеге исемлеген расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз карамагыма алам.

Министр Л.Ю.ГЛУХОВА

Татарстан Республикас
Юстиция министрлыгыны
2015 елның 2 июлендә
01-02/454 номерл
боерыгы белән расланга

**Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан**

**Республикасы дәүләт граждан вазыйфаларын биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулда булган акчаларын һәм кыйммәтле әйберләрен саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) аларны куллану тыелган**

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары**

**исемлеге**

Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалар реестры турында" 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган, Татарста Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры белән Татарстан Республикасы Юстици министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының иң югары төркемен кертелгән вазыйфалар:

юстиция министрының беренче урынбасары;

юстиция министры урынбасары.